# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

# К А Р А Р

21.11.2016 № 105

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 20 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде: “2017 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- Штерә, Ашабаш авылларына янгын гидранты урнаштыру;
- Юлларга вак таш салу: Штырә авылы (Совет ур.), Иске Чүриле авылы (Зеленая ур.), Ашабаш авылы (Күпер ур.);
- Ермоловка авылында чишмә территориясен төзекләндерү;
- Иске Чүриле авылы зираты коймасын алыштыру (мәйданы 150 м);
- Татар Кадрәге авылы зираты өчен металл штакетник сатып алу (мәйданы 150 м);
- Штерә авылы урам утларын карап тоту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга?”

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1137 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-988, бу 86,90 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 976 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 98,79 % тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 12 кеше тавыш бирде, бу 1,21 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип таныырга.

2. “2017 елда Иске Чүриле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 100 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- Штерә, Ашабаш авылларына янгын гидранты урнаштыру;
- Юлларга вак таш салу: Штырә авылы (Совет ур.), Иске Чүриле авылы (Зеленая ур.), Ашабаш авылы (Күпер ур.);
- Ермоловка авылында чишмә территориясен төзекләндерү;
- Иске Чүриле авылы зираты коймасын алыштыру (мәйданы 150 м);
- Татар Кадрәге авылы зираты өчен металл штакетник сатып алу (мәйданы 150 м);
- Штерә авылы урам утларын карап тоту.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга?” соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева